Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАРЫ

2022 елның 11 феврале 93№

Әлки муниципаль районы Советының 2021 елның 1 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 71 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы федераль законнары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Әлки муниципаль районы Советының 2021 елның 1 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 71 номерлы карарына (20.12.21 83№ редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәне әлеге карарга кушымта белән 5 бүлек нигезендә тулыландырырга.

Торак контроле өлкәсендә муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре исемлеген әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

2.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» нигезләмәнең 5 бүлеге 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы торак контроле өлкәсендә муниципаль контроль индикатив күрсәткечләре исемлегенең 18, 20 пунктчасы 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми http://pravo.tatarstan.ru порталы»нда урнаштырырга.http://pravo.tatarstan.ru

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны агросәнәгать комплексы, экологик иминлек һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А.Ф. Никошин